**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Урсаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 24 «06» август 2019 г.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитете 19.02.2019 ел №2 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияне планлаштыру, территорияләрне комплекслы һәм тотрыклы үстерүне тәэмин итү буенча документларны әзерләүне, килештерү һәм раслау өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 03.07.2016 ел № 373-ФЗ Федераль Закон нигезендә,

Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитете 19.02.2019 ел №2 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.5 пунктының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«планлаштыру структурасының элементы-җирлек территориясенең бер өлеше (квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләре Россия Федерациясе

Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык И.А.Абдуллин